ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 532-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова, М.Х. Сәлахов тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 532-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2410-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова,
М.Х. Сәлахов
тарафыннан кертелә

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны педагогик эшчәнлеккә җәлеп итү өчен, шулай ук педагогик хезмәткәрләргә федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән социаль ярдәм күрсәтү максатларында өстәмә дәүләт ярдәме чаралары һәм социаль гарантияләр билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 618-ФЗ номерлы Федераль закон белән педагог һөнәренең абруен күтәрү күздә тотыла, һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны педагогик эшчәнлеккә җәлеп итү өчен, шулай ук педагогик хезмәткәрләргә федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән социаль ярдәм күрсәтү максатларында өстәмә дәүләт ярдәме чаралары һәм социаль гарантияләр билгеләнергә мөмкин дип беркетелә.

Шуңа бәйле рәвештә «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.